Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Трой-Урай авыл җирлеге Советы

# КАРАР №3

Трой-Урай авылы 2017 елның 14 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 28 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15, 20 статьялары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Трой-Урай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 5,19,33 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм аны халык алдында тыңлауларга чыгарырга.

2. Раслау: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2 нче кушымта нигезендә; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлауларны уздыру тәртибе, 3 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча керүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитеты (алга таба-оештыру комитеты) түбәндәге составта оештырырга:

Р.Х.Сафин – - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге башлыгы, оештыру комитеты рәисе;

Вәлиев Ринат Нургали улы-Балык Бистәсе РЭГС слесаре, оештыру комитеты әгъзасы;

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлауларны 2017 елның 30 апреленә 11.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Балык Бистәсе муниципаль районы, Трой-Урай авылы, Мәктәп ур., 9 йорт.

5. Оештыру комитетына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Трой-Урай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре проектын халык алдында әйтелгән тәкъдимнәрне һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Трой-Урай авыл җирлеге Советына икенче укылышта кабул итү өчен кагыйдәләр проектын кертүне тәэмин итәргә.

6. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Трой-Урай авылы, Мәктәп урамы, 13 нче йорт,Кама –буе урамы,9 йорт;Гремячка авылы, Александров урамы 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Трой-Урай авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафин